ҖӘМГЫЯТЬТӘ ҮЗ УРЫНЫҢНЫ ТАБАРГА ТЫРЫШЫРГА КИРӘК.

юды. Кипкәч алып караса, чалбарның юылган балагы икенчесеннән 10-15 сантиметрга кыскарак булып кипкән.

Без беркайчан да студент вакытны бушка уздырмадык. Җәйге яллар вакытында 5-6 студент Татарстан районнары буенча, эш табып, эшләп йөри идек.

**– Сезнең кебек уңышка ирешү өчен, безгә эшне нәрсәдән башларга киңәш итәр идегез?**

– Алай җиңел генә әйтеп булмый шул аны. Һәркемнең үз язмышы. Аллаһы Тәгалә нәрсә насыйп иткәндер бит һәрберебезгә. Киңәш итеп шуны әйтә алам: бала чактан ук күбрәк укырга, абый-апалар, гомумән, олылар биргән киңәшләргә колак салырга, бирелгән белемне үзләштереп барырга тырышыгыз. Яшьтән үк үз юлыгызны табу да мөһим. Бөтен кеше дә җитәкче булып бетә алмый. Шуңа күрә җитәкче булам дип түгел, ә уңышка ирешергә омтылырга, җәмгыятьтә үз урыныңны табарга тырышырга кирәк.

**– Сезнең төп тормыш принцибыгыз нинди?**

– Кызганычка каршы, бу принцип кайчагында үтәлеп тә бетми. Шулай да мин, беренче чиратта, үземнән, әйләнә-тирәдәгеләрдән кешелекле һәм итагатьле булуны таләп итәргә тырышам. Кеше булып тугач, кеше булып кала белергә кирәк! Әйләнә-тирәдәге кешеләрне ихтирам итәргә, алар белән яхшы мөгамәләдә булырга кирәк. Кем генә булып эшләсәң дә, кешеләр белән ягымлы итеп аралаша, сөйләшә белмәсәң, эшләргә авыр булачак. Әңгәмәдәшеңнең яхшы якларын күрергә тырышып, яхшы мөнәсәбәттә булсаң – эшең дә җиңел барачак. Җитәкчегә кешенең холкын белү зарур. Шулай ук төгәл һәм әдәпле булырга кирәк. Шуны онытырга ярамый!



***Энҗе Әхмәтҗанова* (Казан):**

– «Ялкын» балалар редколлегиясе Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры Хамаев Азат Кыям улы белән очрашуда булды. Министр безгә үзенең тормышы, эшчәнлеге белән бәйле бик күп кызыклы вакыйгалар сөйләде. Уңышларының сере таләпчән булуында һәм тәртип яратуында икәнлеген әйтте. «Һәр эшнең үз тәртибе бар, шуңа күрә баштан ук эшкә мөнәсәбәтеңне күрсәтергә кирәк», – диде ул. «Тормышта иң мөһим сыйфат – кешелеклелек. Кеше булып тугансың икән, кеше булып яшәргә кирәк», – дип тә өстәп куйды.

«Уңышларыгызның сере нидә?» дигән соравыбызга, «Уңышка ирешү өчен кечкенәдән тырышып укырга, үзеңнең нинди юнәлештә көчле икәнеңне билгеләп, шул юнәлештә эшләргә, һөнәр сайлаганда да, үзең көчле булган юнәлешне сайларга кирәк», – диде ул. Азат Кыям улы: «Тормышта иң мөһим әйбер ул – сәламәтлек. Сәламәтлек булмаса, уңышка да ирешеп булмый, шуңа күрә физик күнегүләр белән шөгыльләнергә кирәк». Мәсәлән, ул йөзәргә һәм ауга йөрергә ярата икән. Безгә киңәш итеп, ул: «Яраткан эшегез белән шөгыльләнегез. Алдыгызга максатлар куярга, план төзеп эш итәргә өйрәнегез», – диде.





***Алинә Сысоева* (Казан):**

– Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры Азат Кыям улы Хамаевтан сезгә – «Ялкын» укучыларына 3 киңәш:

**1. Һөнәр табу – киңәшле эш.**

«Минемчә, һәрбер ата-ана балага һөнәр табарга булышырга, дөрес юл күрсәтергә тиеш. Дөрес һөнәр сайлау – бик катлаулы эш, кешенең сәләтеннән тора, иң якын кешеләр генә баласын күреп, аңа киңәш бирә ала».

**2. Команда белән бергә булырга кирәк.**

«Мин һәрвакыт үземнең команда белән киңәшләшәм. Һәрбер кеше яңа эшнең төрле якларын күрә. Һәм бу – бик яхшы, чөнки берүзең бар нәрсәне дә күреп, аңлап бетереп булмый».

**3. «Булганның кадерен белегез һәм һәрвакыт алга омтылырга тырышыгыз!»**